| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.06.2016 Казан ш. № 4-1/г

Татарстан Республикасы халкына табигый газны ваклап сату бәяләрен билгеләү турында

“Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында” “Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында” 31.03.1999 №69 -ФЗ Федераль законы нигезендә, 2015 елның 26 октябрендә Россия Федерацииясе Хөкүмәте утырышында расланган, 2016 һәм 2017-2018 планлы елга Россия Федерациясе социаль-экономик үсешенә караган фаразы, “Кулланучыларны газ белән тәэмин итү өлкәсендә ваклап сату бәяләрен тәртипкә салу өчен методик киңәшләрне раслау” 27.10.2011 №252-э/2 Тарифлар буенча Федераль хезмәтнең боерыгы һәм 15.06.2010 №468 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты кагыйдәнамәсе нигезендә, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР чыгарды:

1. Татарстан Республикасы халкына сатылган табигый газны ваклап сату бәяләрен 2016 елның 1 июленнән 5,27 сум/ куб.м (НДС исәпкә алынган) күләмендә билгеләргә.

2. “Татарстан Республикасы халкына сатылган табигый газны ваклап сату бәяләрен билгеләү турында” Татарстан Республикасы Дәүләт комитеты 15.05.2015 №4-1/г карарының 1нче пунктын 2016 елның 1 июленнән үз көчен югалткан дип исәпләргә.

3. Түбәндәге карар рәсми нәшер ителгәннән соң ун көн узгач тулы көченә ия була.

Рәисе М.Р.Зарипов